КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 40

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, 628 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 2 июнь, 331 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәткә төрле хокукларда ия булган юридик затларга ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленә кадәр, Нигезләмәнең 2.3 нче пункты белән күздә тотылган документларны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.

Юридик затларга Татарстан Республикасы мөлкәте турындагы белешмәләрне Реестрга кертү, Реестрдагы белешмәләргә үзгәреш кертү яки аларны Реестрдан төшереп калдыру өчен нигез булып торган документлар белән бергә төрле хокукларда (сатып алу-сату, арендага алу, түләүсез файдалану, җаваплы саклау, ышанычлы идарә итү, концессия шартнамәләре, кабул итү-тапшыру актлары нигезендә) сатып алынган, төрле хокукларда (сатып алу-сату шартнамәләре, кабул итү-тапшыру актлары нигезендә) тапшырылган мөлкәт турындагы белешмәләрне, шулай ук Нигезләмәнең 2.3 нче пункты нигезендә махсуслаштырылган программа продуктында төзелгән мәгълүматларның электрон файллары рәвешендә электрон

чыганактагы мөлкәт турындагы белешмәләргә үзгәреш кертү турындагы мәгълүматны мөлкәт белән эш итү турында карар кабул иткән көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.»;

5 нче пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» дигән сүзләрдән соң «бу карарны тормышка ашыруны тәэмин итә торган хокук актлары кабул итә һәм» дигән сүзләрне өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сорала торган мәгълүматны кертү вакыты – 7 көн.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәдә:

2.2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәткә (алга таба – дәүләт милке) төрле хокукларда ия булучы юридик затлар тарафыннан кәгазь һәм электрон чыганакларда кертелгән бу Нигезләмәнең 2.3 нче пунктындагы документлар;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыклар, Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан чыгармалар, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан чыгармалар;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Реестрны формалаштыру өчен нигез булып торган кәгазь чыганаклардагы документлар аларны даими саклауга законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырганга кадәр Министрлыкта саклана.»;

2.3 нче пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик зат карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлеге һәм дәүләт милкен исәпкә алу картасы шулай ук махсуслаштырылган программа продуктында төзелгән мәгълүматларның электрон файллары (алга таба – мәгълүматлар файллары) рәвешендә кертелә. Мәгълүматлар файлларындагы белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлегендә һәм дәүләт милкен исәпкә алу картасында бирелә торган мәгълүматларга тәңгәл булырга тиеш.»;

2.3.1 нче пунктта:

икенче абзацка «яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язу битенең;» дигән сүзләрне өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күчемсез мөлкәткә юридик зат хокукларын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның, яки Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан чыгарманың, яки Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан чыгарманың (тиешле документ булганда);»;

2.3.2 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. 2.3 нче, 2.3.1 нче пунктларда күрсәтелгән гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүченең сайлавы буенча кәгазь чыганакта язма рәвештә яки

Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин. Гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кәгазь чыганакта язма рәвештә тапшырганда, гаризага теркәлә торган документлар ведомство архивына тапшыру өчен әзерләнә торган документларга карата куела торган таләпләргә туры килергә тиеш. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч түбәндәгеләрнең булуына инана:;»;

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Министрлык түбәндәге очракларда исәп объектын Реестрга кертү процедурасын туктатып торырга һәм бу турыда Гариза бирүчегә хәбәр итәргә тиеш:

кертелгән документлар Нигезләмәнең 2.3 нче һәм 2.3.2 нче пунктларында билгеләнгән документлар исемлеге һәм таләпләр белән туры килмәгәндә;

кертелгән мәгълүматлар Реестрда чагылдырылган мәгълүматлар белән туры килмәгәндә;

кертелгән мәгълүматлар хокук билгели торган документларда күрсәтелгән мәгълүматлар белән туры килмәгәндә;

кертелгән мәгълүматлар ведомствоара хезмәттәшлек итү кысаларында алынган мәгълүматлар белән туры килмәгәндә.

Моның белән бергә, Гариза бирүче 30 көн эчендә элек бирелгән мәгълүматларны раслый торган документлар кертергә тиеш. Мондый очракта исәп объектын Реестрга кертү вакыты озайтыла, әмма озайту вакыты бу абзацта күрсәтелгән документлар кертелгән көннән 30 көннән дә артмаска тиеш.»;

2.5 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаризага теркәлгән документлар бу Нигезләмәнең 2.3 нче һәм 2.3.2 нче пунктларында билгеләнгән документлар исемлегенә һәм таләпләргә туры килмәгәндә.»;

2 нче кушымтада:

8 нче пунктта «атасының исеме» дигән сүзләрдән соң «(булганда)» дигән сүзләрне өстәргә:

«М.У.» дигән сүзләрне «М.У. (булганда)» дигән сүзләргә алыштырырга;

3 нче кушымтада «М.У.» дигән сүзләрне «М.У. (булганда)» дигән сүзләргә алыштырырга;

4 нче кушымтада «Хокук төре» графасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хокук төре, хокукны билгели торган документ (номеры, датасы)»;

5 нче кушымтада «Хокук төре» графасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хокук төре, хокукны билгели торган документ (номеры, датасы)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин